КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 март г.Казань № 263

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2029 елга кадәр иҗтима-гый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 828 нче; 2012 ел, 7 февраль, 89 нчы; 2012 ел, 10 ноябрь, 977 нче; 2013 ел, 19 март, 191 нче; 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2014 ел, 8 июль, 465 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 846 нчы; 2019 ел, 1 февраль, 61 нче; 2019 ел, 28 август, 721 нче; 2023 ел, 7 август, 950 нче; 2023 ел, 30 декабрь, 1768 нче; 2024 ел, 27 гыйнвар, 37 нче; 2024 ел, 25 май, 364 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктта «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат йортлар» сүзләрен «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат йортлар (пансионатлар)» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта «Психоневрология интернатлары» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктта «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йортлары» сүзләрен «Балалар социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республика-сының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 41 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 26 нчы; 2021 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2023 ел, 24 апрель, 519 нчы; 2023 ел, 29 сентябрь, 1203 нче; 2024 ел, 23 октябрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 10 нчы таблицасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«психоневрология интернаты» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йорты» сүзләренә алмаштырырга;

«акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йорты» сүзләрен «балалар социаль хезмәт күрсәтү йорты» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче; 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче; 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче; 2017 ел, 27 июнь, 441 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы; 2018 ел, 26 ноябрь, 1053 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 28 август, 732 нче; 2019 ел, 7 октябрь, 892 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1248 нче; 2020 ел, 15 май, 391 нче; 2020 ел, 18 август, 704 нче; 2020 ел, 25 сентябрь, 873 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1190 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 26 нчы; 2021 ел, 1 февраль, 45 нче; 2021 ел, 21 июль, 627 нче; 2021 ел, 13 август, 719 нчы; 2021 ел, 15 ноябрь, 1075 нче; 2021 ел, 27 декабрь, 1294 нче; 2022 ел, 23 март, 260 нчы; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 16 май, 449 нчы; 2022 ел, 3 август, 755 нче; 2022 ел, 18 ноябрь, 1233 нче; 2023 ел, 27 гыйнвар, 57 нче; 2023 ел, 11 февраль, 140 нчы; 2023 ел, 25 март, 351 нче; 2023 ел, 18 апрель, 489 нчы; 2023 ел, 3 июль, 773 нче; 2023 ел, 24 август, 1010 нчы; 2023 ел, 23 октябрь, 1337 нче; 2023 ел, 15 декабрь, 1628 нче; 2024 ел, 29 гыйнвар, 38 нче; 2024 ел, 7 март, 128 нче; 2024 ел, 1 апрель, 211 нче; 2024 ел, 25 апрель, 275 нче; 2024 ел, 7 май, 309 нчы; 2024 ел, 19 июль, 581 нче; 2024 ел, 23 октябрь, 917 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1267 нче; 2025 ел, 26 май, 359 нчы; 2025 ел, 17 июль, 523 нче; 2025 ел, 25 декабрь, 1148 нче; 2025 ел, 30 декабрь, 1220 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм кайбер дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9.3 пунктта «Психоневрология интернатлары» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктта «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йортлары» сүзләрен «Балалар социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин